| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.02.2025 Казан ш № 121

2025 елда балигъ булмаганнарга һәм эшсез гражданнарга аларны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына финанс ярдәме күләмнәре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» «дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. 2025 елга түбәндәге финанс ярдәме күләмнәрен билгеләргә:

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә аена 2650 сумга тигез күләмдә;

түләүле җәмәгать эшләрендә катнаша торган эшсез гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорында бер кешегә аена 2650 сумга тигез күләмдә;

урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм белем яки квалификация турында документ тапшырылган датадан башлап ел дәвамында эш эзләгән 18 яшьтән 25 яшькәчә булган эшсез гражданнар өчен – аларны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә 4500 сум күләмендә;

гомуми белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар исәбендәге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә аена 4500 сумга тигез күләмдә.

2. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары К.А.Таҗетдинованы җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

ОТДЕЛ ДЕЛО-ПРОИЗВОДСТВА